**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасының кайбер торак пунктлары территорияләрендә һәм Татарстан Республикасы Түбән Кама районының аерым территориясендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле урнаштырылган карантинны бетерү турында

Терлекләрнең котыру белән чирләвенең соңгы очрагыннан соң ике ай узуы, эпизоотиягә каршы һәм профилактик чаралар уздырылу белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының $3^1$ статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. Терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле кертелгән карантинны бетерергә:

а) Татарстан Республикасының түбәндәге торак пунктлары территорияләрендә:

Апас районының Морзалар авылы;

Зеленодольск районының Олы Күлбаш авылы;

Питрәч районының Арышхазда авылы;

б) Татарстан Республикасы Түбән Кама районының Олы Афанас авылындагы Үзәк урамы территориясендә.

2. Үз көчләрен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Питрәч районының Арышхазда авылы һәм Колай авылы территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» 2014 елның 26 ноябрендәге ПУ-1084 номерлы Указының Татарстан Республикасы Питрәч районының Арышхазда авылы территориясендә терлекләр котыру авырулы булганга, аның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертүгә кагылышлы 1 пункты;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының кайбер торак пунктлары территорияләрендә һәм Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» 2014 елның 29 ноябрендәге ПУ-1099 номерлы Указының 1 пунктындагы «а» пунктчасы, «б» пунктчасының өченче абзацы.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2015 ел, 02 февраль
№ ПУ-72